КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 11 август г.Казань № 591

2026 елга Татарстан Республикасында авыл территорияләрендәге, терәк торак пунктлары территорияләрендәге һәм чиктәш территорияләрдәге торакның гомуми мәйданының бер квадрат метры кыйммәтен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын тормышка ашыру турында» 2020 ел, 14 май, 387 нче карары белән расланган «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы кысаларында торак шартларын яхшырту чараларында катнашучылар исемлекләрен төзү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү һәм авыл территорияләрендә торак төзүгә (сатып алуга) социаль түләү бирү турында таныклыклар бирү тәртибенең 19 пункты һәм Торак урыннар наемы шартнамәләре буенча торак алучы гражданнарның исемлекләрен төзү, раслау һәм аларга үзгәреш кертү тәртибенең 21 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елга Татарстан Республикасында авыл территорияләрендәге, терәк торак пунктлары территорияләрендәге һәм чиктәш территорияләрдәге торакның гомуми мәйданының бер квадрат метры кыйммәтен түбәндәгечә расларга:

торак урын наемы шартнамәсе буенча бирелә торган торак төзү (сатып алу) буенча муниципаль районнарның чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә финанс ярдәме күрсәтүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына субсидия күләмен исәпләү өчен 70 983,0 мең сум күләмендә;

Татарстан Республикасындагы авыл территорияләрендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарының торак шартларын яхшырту чаралары кысаларында торак төзүгә (сатып алуга) социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен 35 823,0 мең сум күләмендә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«2024 елга торак урын наемы шартнамәсе нигезендә бирелә торган торак төзелеше (сатып алу) буенча муниципаль районнарның чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә финанс ярдәме күрсәтүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына субсидияләр күләмен исәпләп чыгару өчен Татарстан Республикасындагы авыл территорияләрендә бер квадрат метр гомуми торак мәйданы кыйммәтен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану хакында» 2023 ел, 21 август, 999 нчы;

«2024 елга социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен Татарстан Республикасында авыл территорияләрендә гомуми торак мәйданының бер квадрат метры кыйммәтен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2023 ел, 28 ноябрь, 1526 нчы.

Татарстан Республикасы<br>
Премьер-министры А.В.Песошин